КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 декабрь г.Казань № 1704

2024 елда җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен социаль-икътисадый үстерү һәм аларның муниципаль финансларын савыктыру буенча чаралар күздә тотылып төзелә торган килешүләр турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 137 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44[1] статьясындагы 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы муниципаль районының финанс органы тарафыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенция акчасы булган дотация алучы җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) белән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен социаль-икътисадый үстерү һәм аларның муниципаль финансларын савыктыру буенча чаралар күздә тотылып төзелә торган килешүгә (алга таба шул ук эзлеклелектә – килешү, дотация) түбәндәгеләр тарафыннан кул куела дип билгеләргә:

2024 елда дотация алучы җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан кул куела һәм 2024 елның 15 гыйнварына кадәр финанс органына кертелә;

2024 елның 22 гыйнварыннан да соңга калмыйча, финанс органы тарафыннан.

2. Килешү, 2024 елның 15 гыйнварына кадәр җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан финанс органына 2024 елда дотация алудан рәсми рәвештә баш тарту җибәрелгән очракта, төзелми дип билгеләргә.

3. Килешүдә түбәндәгеләр каралырга тиеш дип билгеләргә:

кушымта нигезендә исемлек буенча дотация алучы җирлек йөкләмәләре;

финанс органының дотация алучы җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан тапшырыла торган, җирлекнең килешүдән барлыкка килә торган йөкләмәләренә кагылышлы документларны карап тикшерү буенча һәм бу документларга бәяләмә әзерләү буенча йөкләмәләре.

4. Дотация алучы җирлекнең җирле администрациясе башлыгына (башкарма-күрсәтмә органы җитәкчесенә) 2025 елның 20 гыйнварына кадәр финанс органына кушымтада каралган җирлек йөкләмәләренең үтәлеше турында хисапны җибәрергә.

5. Җирлек - дотация алучы тарафыннан каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык чаралары сыйфатында билгеләргә:

а) кушымтаның 1 пунктындагы «в» пунктчасында, 3 пунктында – 2025 елга (2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына) бюджет турында Татарстан Республикасы муниципаль районының вәкиллекле органы карары белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән 2025 елга дотация күләмен 2025 елга каралган дотация күләменең 1 процентыннан артмаган, әмма 2024 елга җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап мәгълүматы буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 процентыннан артмаган күләмдә киметү;

б) кушымтаның 2 пунктындагы «а» пунктчасында – 2025 елга (2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына) бюджет турындагы Татарстан Республикасы муниципаль районының вәкиллекле органы карары белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән 2025 елга дотация күләмен әлеге җирлек тарафыннан үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәдәге сайлап куелган вазыйфаи затларның, контроль-хисап органы рәисен, рәис урынбасарын, аудиторларын, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә тотыла торган бюджет ассигнованиеләре күләме әлеге максат өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән чыгымнарны формалаштыру нормативлары нигезендә исәпләп чыгарылган бюджет ассигнованиеләре күләменнән артып киткән, әмма 2025 елга каралган дотация күләменең 1 процентыннан артмаган һәм 2024 елга җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап мәгълүматы буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 процентыннан артмаган күләмдә киметү;

в) кушымтаның 2 пунктындагы «д» пунктчасында – җирлекнең чараларны тормышка ашыруга, муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм күчемсез мөлкәтне муниципаль милеккә сатып алуга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан җирлек бюджетына өстәмә финанс ярдәме күрсәтүне туктатып тору.

6. Дотация алучы җирлек түбәндәгеләр өчен җаваплылыктан азат ителә дип билгеләргә:

әлеге килешүгә имза куйган җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-күрсәтмә органы җитәкчесе) вәкаләтләрен туктаткан һәм 2024 елда башка зат җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе)

(җирлекнең җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) вазыйфаларын вакытлыча башкаручы) итеп сайланган (билгеләп куелган) очракта, килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә;

2024 елда җирлек тарафыннан әлеге йөкләмәләрнең үтәлешенә комачаулый, җиңеп чыга алмый торган вакыйгалар (федераль характердагы гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килгән очракта, кушымтаның 1 пунктындагы «в» пунктчасында һәм 2 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен;

2023 ел белән чагыштырганда 2024 елда тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрне бүлү методикасына үзгәреш кертү сәбәп булып торган әлеге арту чикләрендә субвенция күләмен арттыруга бәйле рәвештә әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирлекнең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре саны арттырылган очракта, бу карар кушымтасының 2 пунктындагы «в» пунктчасында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен.

7. Финанс органына 2024 елның 15 гыйнварына кадәр дотация алучы җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-күрсәтмә органы җитәкчесе) тарафыннан тапшырылмаган очракта, түбәндәгеләрне билгеләргә:

күрсәтелгән вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган килешүне, 2024 елга каралган дотацияләр күләме Татарстан Республикасы муниципаль районы вәкиллекле органының 2024 елга (2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына) бюджет турында карары белән расланган дотацияләрне бүлүгә үзгәрешләр кертү юлы белән 10 процентка кими;

2024 елда дотация алудан рәсми рәвештә баш тартуны, 2024 елга каралган дотация күләме Татарстан Республикасы муниципаль районы вәкиллекле органының 2024 елга (2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына) бюджет турында карары белән расланган дотацияләрне бүлүгә үзгәрешләр кертү юлы белән тулы күләмдә кыскара.

8. Бу карар 2024 елда җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль районнарының финанс органнары белән килешүләр төзү максатларында кулланыла һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 декабрь, 1704 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенция акчалары финанс тәэминаты чыганагы булган, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен социаль-икътисадый үстерү һәм финансларын сәламәтләндерү буенча чаралар каралган килешүгә кертелергә тиешле җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан дотация алучы җирлек йөкләмәләре исемлеге

1. Җирлекнең дотациялелеге дәрәҗәсен киметүгә һәм җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру буенча түбәндәгеләр карала торган йөкләмәләр:

а) 2024 елның 1 ноябренә кадәр җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган салым ташламаларының (түбәнәйтелгән салым ставкаларының) нәтиҗәлелеген Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр нигезендә бәяләүне үткәрү;

б) 2024 елның 20 ноябренә кадәр җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган салым ташламаларының (түбәнәйтелгән салым ставкаларының) нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук, әгәр салым ташламаларының (түбәнәйтелгән салым ставкаларының) нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре буенча нәтиҗәле булмаган салым ставкалары (түбәнәйтелгән салым ставкалары) ачыкланган булса, нәтиҗәле булмаган салым ставкаларын (түбәнәйтелгән салым ставкаларын) гамәлдән чыгару планын Татарстан Республикасы муниципаль районының финанс органына (алга таба – финанс органы) кертү;

в) чагыштырма шартларда 2023 елга бюджет үтәлеше дәрәҗәсе белән чагыштырганда 2024 елга җирлек бюджетын үтәү йомгаклары буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре артуны тәэмин итү (процентта);

г) җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан түбәндәгеләрнең Россия Федерациясе бюджет законнары таләпләренә туры килү-килмәве турында финанс органына бәяләмә җибәрү:

әлеге проектларны җирлекнең вәкиллекле органына керткәнгә кадәр 2024 елга (2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына) җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында җирлекнең вәкиллекле органы карарлары проектлары;

күрсәтелгән проектны җирлекнең вәкиллекле органына керткәнче вәкиллекле органынның 2025 елга (2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына) бюджет турында карар проекты.

Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына бу пунктчада күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын, финанс органы тәкъдимнәрен исәпкә алмыйча, җирлекнең тиешле вәкиллекле органына кертмәскә.

2. Бюджетны консолидацияләүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләр:

а) соңгы өчтән ике хисап финанс елы дәвамында бюджетында Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләрнең өлеше җирле бюджетның үз керемнәре күләменең 5 процентыннан артып киткән җирлек тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәис урынбасарлырының, аудиторларның Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәис урынбасарлырының, аудиторларның Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын үтәү;

б) муниципаль учреждениеләрнең вакытында түләнмәгән кредит бурычларын барлыкка килүне булдырмау;

в) җирлекнең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре санын арттырмауны, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлү аркасында хезмәткәрләр санын арттырырга кирәк булган очракта, җирлектәге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре санын арттыру турында җирлектәге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары проектларын кабул иткәнгә кадәр аларны финанс органына килештерүгә җибәрүне тәэмин итү;

г) Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан бирелгән дотацияләрне Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетында каралган күләмнән артмаган күләмнәрдә керемнәр составына кертеп, җирлекләр бюджетларын раслау;

д) Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым түләүләре буенча бурычларны кыскарту чараларын үткәрү, шул исәптән үткән елның шул ук чоры белән чагыштырганда һәр кварталның 1 нче көненә салым түләүләре буенча бурычлар (банкротлык процедурасында булган һәм ябыла торган салым түләүчеләрнең недоимкасыннан тыш) артуны булдырмау, салым түләнергә тиешле елдан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр җирлекнең җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләре, физик затлар тарафыннан түләнергә тиешле салымнар буенча бурычларны тулысынча каплауны тәэмин итү;

е) муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан норматив финанслау принципларын үтәү;

ж) хезмәткәрләрнең тарификациясе буенча исәпләнгән күләмнән ким булмаган күләмдә хезмәт өчен түләү фондын планлаштыруны исәпкә алып, муниципаль

бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын формалаштыру;

з) җирлекнең җирле үзидарә органнары рәсми сайтларында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 2024 елга (2024 елга һәм 2025, 2026 елларның план чорына) җирлек бюджеты турында карарлар, 20241 елга (2024 елга, 2025, 2026 еллар план чорына) җирлек бюджетына үзгәрешләр кертү турында карарлар урнаштыру;

и) ай саен җирлек бюджетының үтәлеше турындагы хисапларны җирлектәге җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштыру.

3. Муниципаль финанслар белән идарә итүнең сыйфатын яхшырту кысаларында чараларны гамәлгә ашыру буенча түбәндәгеләр карала торган йөкләмәләр:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $92^1$ статьясында билгеләнгән җирле бюджет кытлыгының иң чик күрсәткеченә карата таләпләрне үтәү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 106 статьясында билгеләнгән муниципаль бурыч алуларның иң чик күләменә карата таләпләрне үтәү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән таләпләрне үтәү;

җирлек бюджеты турындагы карарда җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганагы буларак каралган, Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җәлеп итүгә планлаштырылган бюджет кредитлары Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирү турында карар кабул ителгән бюджет кредитлары (җирле бюджетлар счетларындагы акчаны калган өлешен тулыландыруга бюджет кредитларыннан тыш) суммасыннан артыграк булмау;

һәр айның 1 нче көненә карата финанс органына тапшырыла торган җирлекнең бурыч китабы мәгълүматы нигезендә җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән бурычы булмау.

4. Бу Исемлектә каралган йөкләмәләр үтәлмәгән очракта (бу Исемлекнең 1 пунктындагы «в» пунктчасында, 2 пунктындагы «а» һәм «д» пунктчасында, 3 пунктында каралган йөкләмәләрдән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан җирлектәге җирле үзидарә органнарының гамәлләре (гамәл кылмавы) әлеге йөкләмәләрне бозуга китергән вазыйфаи затларына карата дисциплинар җаваплылык чараларын куллану буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге йөкләмәсе.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 декабрь, 1704 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составы

| | |
|---|---|
| Кузюров Равил Әфраим улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры, коллегия рәисе |
| Зарипов Илгизәр Наил улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары, коллегия рәисе урынбасары |
| Коллегия әгъзалары: | |
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары – әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы |
| Гомәров Рәис Кәлимулла улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры урынбасары |
| Зарипов Илгиз Нәҗип улы | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Кәшафиев Илнур Рафаэль улы | «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе-урманчысы |
| Колчин Иван Петрович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Кондратова Наталья Владимировна | Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры |
| Рәхмәтуллин Илһам Гайдулла улы | «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе-урманчысы |
| Фәсхетдинов Марат Гайсә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Фәхраҗиев Рим Фазыл улы | «Лубян урман техника көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директоры |
| Хәйруллин Шамил Мәхмүт улы | «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе-урманчысы |
| Ягъфәров Азат Фердинанд улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |